**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы**
**Теләнче-Тамак авыл җирлеге составына керүче Теләнче Тамак авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

28 ноябрь, 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Теләнче-Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, 2024 елның 28 нче ноябрендә узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән түбәндәге мәсьәлә буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2025 елда яшәү урыны буенча Теләнче-Тамак авыл җирлеге Теләнче Тамак авылы территориясендә теркәлгән һәр бәлигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:
**«- торак пункт территориясен төзекләндерү (Теләнче-Тамак авылы Татарстан урамы буенча гомуми файдаланудагы территорияне төзекләндерү; мәдәният йорты территориясендә балалар мәйданчыгын төзекләндерү балалар уен элементларын сатып алу, урнаштыру, Сабантуй үткәрү урынын төзекләндерү агачларны кисү, стоянкаларны төзекләндерү)**
**- урамнарны яктырту эшләрен башкару (Теләнче-Тамак торак пунктында урамнарны яктыртуны ремонтлау өчен электр җиһазлары һәм комплектлау элементлары (яктырткычлар) сатып алу)**
**- торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( Теләнче Тамак авылы Красноармейская урымнда юл ремонты) ».**

«ӘЙЕ» «ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 798 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 429 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
**«Әйе»** позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 429 кеше тавыш бирде;
**«Юк»** позициясе өчен җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены **карар бирде:**
1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Теләнче-Тамак авыл җирлеге Теләнче Тамак авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.